КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 июль г.Казань № 564

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары уңышларга ирешкәннәре өчен спортчыларга һәм тренерларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2018 ел, 20 февраль, 98 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары уңышларга ирешкәннәре өчен спортчыларга һәм тренерларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2018 ел, 20 февраль, 98 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

5 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган спортта югары уңышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына айлык стипендияләр күләмнәрен (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 20 февраль, 98 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 10 июль, 564 нче
карары редакциясендә)

Спортта югары уңышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәүче спортчыларына айлык стипендияләр күләмнәре

| Ярышлар исеме | Айлык стипендияләр күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | I урын | II урын | III урын |
| Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары | 90 000 | 70 000 | 50 000 |
| Дөнья чемпионаты | 60 000 | 50 000 | 40 000 |
| Европа чемпионаты | 50 000 | 40 000 | 30 000 |
| Яшүсмерләр олимпия уеннары, дөнья беренчелеге | 30 000 | 25 000 | 20 000 |
| Европа яшүсмерләр Олимпия фестивале, Европа беренчелеге | 25 000 | 20 000 | 15 000 |
| Россия чемпионаты | 20 000 | 15 000 | 10 000 |
| Россия беренчелеге (яшьләр, юниорлар), Россия яшьләре спартакиадасы | 12 000 | 9 000 | 6 000 |
| Россия беренчелеге (14 яшьтән һәм өлкәнрәк егетләр һәм кызлар), Россия укучылары спартакиадасы | 6 000 | 4 440 | 3 000 |

Искәрмәләр:

1. Россия Федерациясе Спорт министрлыгының төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чараларының бердәм календарь планына кертелгән халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында призлы урыннарны алган спортчыларга айлык стипендияләр түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

спортның олимпия булмаган төрләре буенча – бу расланган стипендияләр күләмнәреннән 25 процент;

спортның Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары программаларына керми торган олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия төрләре дисциплиналары буенча – бу раслаган стипендияләр күләмнәреннән 50 процент.

2. Айлык стипендияләр үткән календарь елы йомгаклары буенча спортчы күрсәткән иң югары бер нәтиҗә өчен бер календарь елы дәвамында түләнә.